**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ СТАРОКУТУШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Свежухина, дом 33, с.Старые Кутуши,
423116

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИСКЕ КОТЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Свежухин урамы, 33нче йорт, Иске Котыш
авылы, 423116

Тел(84396)2-72-47 Skut.Cmn2@tatar.ru

**№ 124** **05.03.2025 ел**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Иске Котыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге
Советының 2012 елның
28 декабрендәге «Татарстан
Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Иске Котыш
авыл җирлегенең җирдән
файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләрен раслау турында»
№ 46 карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 елның 26 декабрендәге № 485-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 28 декабрендәге 46 номерлы карарына (Советның 15.11.2018 ел, №107; 17.06.2021 ел, № 25, 19.08.2021 ел, №28, 17.05.2022 ел, №50 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктның 2,3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Автомобиль юлының юл буе полосалары - беренче, икенче яисә өченче категорияле автомобиль юлына бүленгән полосага ике яктан да якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау, карап тотуның, автомобиль юлының үсеш перспективаларын исәпкә алып, аның сакланышының нормаль шартларын тәэмин итү максатларында җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләренең өлешләреннән) файдалануның махсус режимы билгеләнә торган территорияләр.

Зона параметрлары һәм зонадагы эшчәнлекне чикләү «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә билгеләнә.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.К.Митякин